АЛТЫН УК БУЛМАСА ДА...

Яңа уку елыннан башлап мәктәпләрдә көмеш медальләрне кире кайтарырга җыеналар

> 5

БЕРЕНЧЕ ОЧКО

«Рубин» премьер-лигадагы беренче матчта җиңүне кулдан ычкындырды

> 5

МАРАТ КӘБИРОВ:

«Мин авылны сагынам. Әллә нинди сәер сагыну бу. Теш сызлавы сыман сагыну»

> 6

МАТУРЛЫК ТУГАНДА

Балтач районында яшәүче Гариповларның үз җәннәт бакчасы бар

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 105 (29072) | Сишәмбе | 25 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ИҢ МӨКАТДӘС НӘРСӘ – ЭШ

ХЕЗМӘТ БАЗАРЫНДАГЫ ВАЗГЫЯТЬ

Мәшгульлек

Республикада эшсезләр саны кимегән. Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының яңа мәгълүматлары шул хакта сөйли. Шул ук вакытта предприятиеләр, эшче куллар җитми, дип чаң суга. Республика барыннан да бигрәк машина йөртүчеләргә, инженерларга һәм җыештыручыларга мохтаҗ. «ВТ» хәбәрчесе хезмәт базарындагы вазгыятьне белеште.

tatarstan.ru

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, апрель – июнь айларында республикада эшсезләр саны 42,5 мең булган. Ел башыннан бирле әлеге сан 1,3 мең кешегә кимегән.

19 июльгә китерелгән саннар буенча, республикада 6138 эшсез теркәлгән. Чагыштыру өчен: 1 гыйнварда андыйларның саны 7,5 мең булган. Аерма әллә ни зур булмаса да, сөенергә җирлек бар.

Эшлим дигән кешегә эш бар анысы. «Россиядә эш» порталы төрле һөнәрләр буенча 34 меңнән артык буш урын тәкъдим итә әнә. Аларның күпчелеге (22,2 проценты) җитештерү тармагына туры килә. Һәрвакыттагыча, эшче һөнәрләргә ихтыяҗ зур. Республикада җыештыручылар, машина йөртүчеләр, инженерлар җитми.

Җитештерүдән тыш, төзелеш һәм күчемсез милек (2,8 мең эш урыны), транспорт (1,9 мең эш урыны), мәгариф һәм фән, сәламәтлек саклау (1,8 мең эш урыны) өлкәләре дә белгечләргә кытлык кичерә. Кесә ягын калынайтырга теләгәннәрне сату һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү, азык-төлек сәнәгате, консалтинг хезмәтендә дә көтәләр. Болай булгач, 6138 эшсезне рәхәтләнеп эшкә урнаштырып бетереп булыр иде кебек тә бит... Канәгатьләндерерлек, лаеклы хезмәт хакы булса, эшсезләрнең шактые җиң сызганыр иде.

Акча димәктән, ихтыяҗ зур булган һөнәрләр арасында иң күп акчаны электр белән эретеп ябыштыручылар ала икән. Аларның уртача эш хакы – 45292 сум. Беренче өчлеккә кергән һөнәрләр арасындагы инженерларныкы – 39186 сум. Сүз уңаеннан, республикада әлеге белгечләр өчен 1171 эш урыны бар. Машина йөртүчеләргә (2013 эш урыны) – 36529 сум, җыештыручыларга (2090 эш урыны) 19124 сум күләмендә уртача хезмәт хакы вәгъдә итәләр.

Казанда яшәүче 30 яшьлек Резедә Гәрәеваның эшкә урнашып йөргән чагы. Һөнәре буенча ул – пешекче.

– Укып бетергәннән бирле эш алмаштырам. Бер генә җирдә озак эшли алмыйм. Иң күп эшләгәнем – 3 ел. Кызык түгел, җан тартмый башлый. Бертөрлелектән тиз туям. Эш табу минем өчен авыр түгел үзе, кешеләргә дә бик тиз ияләнәм. Мәктәп ашханәләрендә, ресторааннарда, ял йортларында эшләгәнем бар. Урынына карап, кайбер җирдә сменалап түлиләр, кайсында айга бер. Бүген дә әңгәмәгә бардым әле. Шалтыратырбыз, диделәр. Әлегә хәбәр көтәм, – дип сөйләде ул.

Хәзерге вакытта чыгарылыш сыйныф укучыларының да тынгысыз чоры: югары уку йортларыннан кабул итү буенча җавап көтәләр. Superjob сораштыруы буенча, быел абитуриентлар арасында иң популяр юнәлешләр – мәгълүмат технологияләре (абитуриентларның 28 проценты шул юнәлештә укырга керергә теләвен әйткән), медицина (13 процент) һәм инженерлык (9 процент).

Кукмара районының Вахит авылы егете Алмаз Нигъмәтҗанов та ай-ти өлкәсен сайлаган.

– Гаризаны биш уку йортына тапшырдым. Күптән түгел аттестатны Казан милли тикшеренү техник университетында (КАИ) калдырып кайттым. БДИны информатика фәненнән биреп, IT, роботлаштыру системалары юнәлешләрен сайладым. Без бит – XXI гасыр балалары. Технологияләр, инновацияләрдән башка тормышны күз алдына да китереп булмый. Хәзерге вакытта бик актуаль. Аннан соң IT белгечләргә ихтыяҗ зур, хезмәт хаклары да әйбәт. Тик акча ягыннан отышлы булса да, эшеңнән канәгать булмыйсың икән, мәгънәсе юк дип уйлыйм. Һөнәрең акча китерергә генә түгел, уңай хисләр дә уятырга тиеш, – диде Алмаз.

Ләйсән САФИНА

Кече шәһәрләр матурая

Татарстанның тугыз шәһәреннән икесе кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләрдә уңайлы мохит булдыру буенча бөтенроссия бәйгесендә җиңгән. Болар – Баулы һәм Кукмара. Бәйге нәтиҗәләре буенча республикага яңа парк-скверлар булдыру өчен барлыгы 164,4 миллион сум күләмендә грант биреләчәк.

Баулы халык саны 20 меңнән 50 меңгә кадәр булган кечкенә шәһәрләр категориясендә җиңүче дип танылган. Анда 6 нчы мәктәп территориясе, Пионер һәм Октябрь мәйданы урамнары, автовокзал янындагы мәйдан яңартылачак. Ә инде Кукмара халык саны 20 меңгә кадәр булган кече шәһәрләр буенча беренчелеккә чыккан. Бу шәһәрдә урамнар һәм хастаханәләр тирәсе яшелләндереләчәк, ямьләндереләчәк. Моннан тыш Свияжск авылы заявкасы Россия төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллинның Рәхмәт хаты белән билгеләп үтелгән.

Быел Татарстан бу бәйгедә инде сигезенче тапкыр катнаша. 2018–2022 еллар чорында бездән барлыгы 40 җәмәгать урыны җиңүче дип табылган, 32се яңартылган да инде. Федераль бюджеттан бирелгән грантларның гомуми күләме 2,7 миллиард сумнан артып киткән.

Табигый янгын дәһшәте

Россия урманнары һәм далаларының 1 миллион гектардан артыграк мәйданы янгынга дучар булган инде. ТАСС хәбәренә караганда, бүген 19 төбәкнең урманнарында барлыгы 267 урында ут әле һаман дөрли. Галәмнән термик нокталар (чүп яну, урманда, далада, башка урында ут чыгу кебек очраклар) саны арту күзәтелә. Әстерхан, Волгоград өлкәләрендә һәм Калмыкиядә янгын чыгу куркынычы зур.

Узган атнада Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы барлыгы 5,7 мең техноген янгын (җитештерүдә, торак секторында хуҗалык эшчәнлегенә бәйле янгын) очрагын теркәгән. Янгын сүндергәндә барлыгы 336 кеше үлемнән коткарылган. Һәлак булучылар саны 19 процентка кимегән.

Тагын чиллә

Якын араларда Татарстанда янә +30 градустан югарырак эсселек көтелә. Синоптиклар хәбәренә караганда, чәршәмбе – 26 июльдән кыздыра башлаячак. Бу көнне көндез термометрның терекөмеш баганасы +25...+30 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнлә +11...+16 градус. Яшенле яңгыр, секундына 15–20 метрга кадәр көчле җил. Пәнҗешәмбе – 27 июльдә тагын да эссерәк: көндез +29...+34 градус. Төнлә +11...+16. Якшәмбе – 30 июльдә бераз гына салкынча: +29 градус.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, җомга һәм шимбә – 28, 29 июльдә эссе һава саклап, температура +30...+35 градус чикләрендә тирбәләчәк. Урыны белән яшенле яңгырлар булырга мөмкин.

Куркыныч чир көчәйгән

Татарстанда беренче яртыеллыкта тычкан бизгәгеен йоктыручылар саны 100 мең кешегә 10,44 күрсәткечен тәшкил иткән. Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе хәбәр иткәнчә, күпьеллык уртача күрсәткечтән (5,94) – 1,8 тапкыр һәм узган елның шушы ук чорындагы (4,91) белән чагыштырганда 2,1 тапкыр зуррак сан бу.

Быел гыйнвардан июльгә кадәр республикада куркыныч авыру йоктыруның 391 очрагы теркәлгән. Узган елның шушы ук чорында 182 кеше чирләгән булган.

Иң күп чир очраклары июньгә туры килгән: бу айда 168 кешенең бизгәк ияртүе расланган. Авыру урманда күбрәк йога (чирләүчеләрнең 43 проценты). 38 кеше бакчачылык ширкәтендә йоктырган.

Белгечләр аңлатып үткәнчә, чирне гадәттә кимерүчеләр тарата. Яз иртә килеп, һаваның гадәттәгедән алданрак җылынуы, шулай ук профилактик чараларны үтәмәү инфекция көчәюгә китергән. Тычкан бизгәгенә каршы вакцина юк. Чирне булдырмас өчен, шәхси гигиена таләпләрен үтәү һәм кимерүчеләрне юк итәргә тырышу кирәк.

Көн кадагында

Әле ярый өмет бар

Авыл салмак кына үз мәшәкатьләре белән яшәвен дәвам иттерә. Абзарында терлеге булганнар печән чабу, кайтарту, ашлык юнәтү эшләре белән мәш килә. Иң кирәк чакта тансык яңгырлар явып сөендергән кайбер авылларда күкрәп үскән үләннәр өчен шөкер иткәндә, икенчеләрендә печән бәяләренең өскә үрмәләвенә, ә сөтнеке күтәрелмәгәнгә кәефләре кырылган чак. Көзгә терлек саннарын киметергә ниятләп торучылар да байтак. Авыл халкы нәрсәгә өметләнә? Без аларның хәлләрен белештек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Миләүшә БУЛАТОВА
(Апас районының Олы Бакырчы авылы):

– Быел февральдә сөт бәяләре төпкә төшеп утыргач, аны җыючыга тапшырмый башладык без. Кибетләргә куеп сатабыз. Каймагын, эремчеген, кортын да ясыйм. Мәшәкате күп, тик файдасы да бермә-бер артыграк. Хәзер шәхси хуҗалыкларга бер килограмм сөт өчен 15 сум акча түлиләр. Соңгы тапкыр шул бәядән аена 41 мең сум акча алган идек. Хәзерге вакытта алты сыерның сөтен эшкәртеп саткач, аена 120 мең сум кереп бара. Менә бу айда сигез сыер савам. Шулкадәр сөтне урнаштырып, шактый керем алгач, сыерларны киметергә уйламыйбыз, чөнки алар – безнең төп яшәү чыганагы. Ә менә башкаларның кәефләре бүтәнчә. Бөтен кеше дә сөтен эшкәртеп сата алмый бит. Димәк, аларның керемнәре дә аз. Андыйлар, көзгә терлекләрне бетерәбез, дип торалар. Безнең якларда печәннең бер рулоны 2000 сум тора. Без, мәсәлән, аны кыйммәтсендек, алмадык, чөнки узган елгы запасыбыз күп. Салам алырга дип торабыз. Килосын 8 сумнан 7 тонна арпа сатып алдык. Моннан тыш, без жом алабыз. Кышны шуның белән чыгабыз. Ләкин керемнәр чыгымны каплап бара. Дөрес, моның өчен бик тырышырга, иренмәскә кирәк инде.

Ахыры 6 нчы биттә >

Сүзгә-сүз

Рөстәм ГАРИПОВ, Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы:

Сез автомәктәптә ярты ел уку күп, дисез. Ә без, бәлки, аздыр да, дип уйлыйбыз. Чөнки аннары алар гомерләре буе транспорт белән идарә итәчәк. Беренчедән, йөртергә өйрәнергә кирәк. Икенчедән, курсантлар шуны аңларга тиеш: алар имтиханны инспектор өчен түгел, ә үзләре өчен тапшыра.

(«Реальное время»га әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ТОРМЫШ ДӘРӘҖӘСЕ

Белгечләр ил төбәкләрендә урта хәлле гаиләләр санын исәпләп чыгарган. «РИА Новости» агентлыгы төзегән рейтингта беренче урынны Ямал-Ненец автономияле округы алган. Татарстан – 26 нчы урында.

	төбәк	урта хәлле гаиләләр, %
1	Ямал-Ненец АО	39,2
2	Чукотка АО	32,5
3	Магадан өлкәсе	31,9
4	Мәскәү	30,0
5	Сахалин өлкәсе	28,7
...		
26	**Татарстан**	**9,2**
...		
	Россия буенча	**11,0**

Урта хәлле дип автомобиль һәм фатир сатып алырга, ял итәргә бару мөмкинлегенә ия булган, машина һәм торак өчен айлык кредит акчасын түләгәч тә, һәр кешегә ким дигәндә төбәктәге яшәү минимумының икеләтә күләмендә акчасы калган, ай саен күпмедер мая туплый алган гаилә санала.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЦИНЬ ГАН КАЯ КИТКӘН?

Планетадагы вазгыятькә Путин сүзләре белән бәя бирик: «Дөньядагы хәл тотрыклылыктан ерак тора, иске конфликтлар тирәнәя, яңалары пәйда була». Чынлыкта, Путин билгеләмәсе дә глобаль мөнәсәбәтләрне тулысынча колачлап бетерми. Җир шарында вазгыять моңарчы беркайчан да булмаганча катлаулы.

Үткән атнада Кытайның тышкы эшләр министры Цинь Ганга бәйле яңалыклар шау-шу кубарды. Цинь Ган инде берничә атна рәттән күренми һәм аның кайда икәнен белгән кеше юк. Кытай чынбарлыгы шартларында бу дәүләт чиновнигының эшләре шәптән түгел дигәнне аңлата. Андагы түрәләр гадәттә зур җинаять эше ачылыр алдыннан шулай юкка чыга. Бөекбританиянең тышкы эшләр министры Клеверли хәтта июль азагында Пекинга булырга тиешле визитын да Ган юкка чыгу сәбәпле туктатып торды.

Аның каравы Кытайга Америка тышкы сәясәтенең патриархы – 100 яшьлек Генри Киссинджер шәхси визит белән килде. Совет чоры кешеләренә бик таныш исем бу. Үткән гасырның җитмешенче елларында Америка Президентының Милли куркынычсызлык буенча киңәшчесе һәм АКШның Дәүләт секретаре булып торган бу шәхеснең кайчандыр Кытайга булган визиты АКШ – Кытай, СССР – Кытай мөнәсәбәтләрен тамырдан үзгәрткән иде. Океан арты державасы белән кытайлар дуслык мөнәсәбәте үстерә башлады, ут күршеләре булган советлардан нык ерагайдылар. Бүгенге Кытай дөньякүләм держава роленә дәгъва кыла икән, бу Киссинджер эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйләнгән. Си Цзиньпинның әлеге визит уңаеннан Американың карт сәясәтчесенә биргән бәясен карагыз: «Киссинджерның Пекин – Вашингтон мөнәсәбәтләрен нормальләштерүгә керткән өлеше ике илгә файда китереп кенә калмады, дөньяны үзгәртте», – диде ул.

Күз алдыгызга гына китерегез: сәясәт ветераны, карт бер пенсионер чит илгә килә һәм аны башта илнең тышкы сәясәтен билгеләүче дәүләт чиновнигы кабул итә, аннан соң держава лидеры үзе очрашып, озаклап сөйләшә. «Без беркайчан да үзебезнең элекке дустыбызны онытмаячакбыз», – дигән җылы сүзләр әйтә. Си нәкъ менә шулай диде һәм Пекинда ике ил мөнәсәбәтләренең Ричард Никсон вакытын сагынуларын белдерделәр.

Киссинджер беренче тапкыр Кытайга килгән 1971 елда ике ил арасында хәтта дипломатик мөнәсәбәтләр дә юк иде әле. 1972 елның февралендә Никсон визиты вакытында Кытай һәм АКШ уртак коммюнике игълан иттеләр, соңыннан Шанхай коммюникесы дип аталган ул документ АКШның бер Кытайны тануын теркәп калдыра.

Американнар – соңгы көннәрдә Күк асты илендә еш кунак. Финанс министры Йелленнан соң Керри – климат үзгәрешләре буенча Президентның махсус вәкиле дә булып китте. Йөзенче тапкыр Кытайга килгән йөз яшьлек Киссинджер мөнәсәбәтләрдә кискен борылыш ясый алырмы – анысы әлегә мәгълүм түгел, әмма шуңа омтылыш зур, монысы – факт.

Россиядә

СТРЕЛКОВНЫ УТЫРТАЛАРМЫ, КАЛАМЫ?

Үткән атнада Россиянең эчке сәясәтен билгеле торган берничә мөһим вакыйга булды. Үзәк банк төп ставканы йөз база пунктына – бер процентка күтәрде. Төп ставканың югарыга хәрәкәте икътисадның тотрыклы булмавын дәлилли. Гадәттә бу инфляцияне авызлыклау һәм сумның девальвациясен туктату максатыннан башкарыла, әмма реаль җитештерүгә аяк чала. Банк депозитлары күбрәк табыш вәгъдә итә башлый, кредитлар кыйммәтләнә. Хөкүмәт рәсми рәвештә бюджетны кисәчәген, әҗәткә акча җыячагын әйтте. Долларның 90 сумлык курсы да – Финанс министрлыгы куйган максат.

Пригожинның ярымфетнәсеннән соң Россия элиталары арасында кайбер мәсьәләләрдә каршылыклар кискенләшүе күзгә чалына башлады. Үткән атнада мәгълүмат кырында элекке ФСБ полковнигы, Донбасста 2014 елда башланган вакыйгаларда төп роль уйнаучыларның берсе, Донецк Халык Республикасының оборона министры булып торган Игорь Стрелков-Гиркинның кулга алынуы турында хәбәрләр күренде. Башта ультрапатриотлар тавыш кубарды, аннан соң хәбәрләр рәсми «Российская газета»да да бирелде. Хәзерге вакытта «выслуга лет» буенча пенсиядә булган Стрелков махсус хәрби операциянең барышыннан канәгать түгел иде. Россиянең хәрби җитәкчелеген рәхимсез рәвештә тәнкыйтьләде, «Ачулы патриотлар» дигән оешманың идея җитәкчесе ролен үтәде, хәтта Путин адресына да усал тәнкыйть сүзләре яудырды. Гади кеше булса, аны әллә кайчан «армияне дискредитацияләү» өчен гаепләп утыртырлар иде, әмма махсус хәрби операция тарафдары һәм 2014 елгы «рус язы»ның башында торучы буларак кагылмадылар. Украина конфликтына аның карашы Пригожинныкы белән тәңгәл килә, әмма икесе үзара дошманнар иде.

Стрелков-Гиркинның кулга алынуы Кремль сәясәтендә нечкә борылыш башлануын күрсәтә. Бертуктаусыз конфликтны кискенләштерүгә чакырган, тулы мобилизациягә өндәгән бу шәхеснең интернетта миллионлы аудиториясе бар, әмма аны яклап, суд бинасы янына берничә дистә генә кеше килде. Бу да турбопатриотларның активлыгы ни дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Диван сугышлары алып барырга кирәк булса – рәхим итегез, әмма чын конфликтлардан безне ерак тотыгыз – төп юнәлеш шул. Үзләрен «Ачулы патриотлар» дип атаучылар Киев – Мәскәү конфликтын сөйләшүләр кысасына кертергә комачаулыйлар иде. Кремльнең алардан арына башлавы яхшы фал дип саныйк. «Российская газета» Стрелковның Лефортово төрмәсендә ике кешелек камерада утыруын әйтә. Рәсми булмаган хәбәрләр, камерада суыткыч һәм телевизор бар, диләр. Стрелков үзе, сәламәтлеге начар булуын сәбәп итеп, өй тоткынлыгы сораган иде – тыңламадылар. Безгә килеп ирешкән рәсми булмаган хәбәрләр җәнҗаллы полковникның үзен буйсынучан тотуын, таякны бөгеп җибәрүен тануын әйтәләр. Сәяси эшчәнлектән читләшергә сүз бирә, дигән сүзләр дә бар. Әлегә аның киләчәк язмышы билгеле түгел. Хөкем карары Мәскәүнең ни дәрәҗәдә борылыш ясарга әзер булуын күрсәтер, мөгаен.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ – АВЫЛ ХЕЗМӘТЧӘННӘРЕНӘ:

«ИЛ СЕЗГӘ ТАЯНА»

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, гадәттәгечә, республика районнарда урып-җыюның барышын бәяләде, авыл хуҗалыгы тармагы хезмәткәрләре белән аралашты.

Алексеевск. Басуларны очкыч белән карап чыкканнан соң, Рөстәм Миңнеханов Сакон авылындагы ашлык терминалында тукталды. Әлеге корылма быел гына кулланышка тапшырылган. Биредә елына 300 мең тонна ашлык суктырырга мөмкин. Аны бөтен Кама аръягыннан китерәләр.

Кыркүл авылында исә авыл хезмәтчәннәре, хуҗалык җитәкчеләре, авыл җирлеге башлыклары белән очрашу булды. Билгеле, сүз урып-җыю эшләре турында барды. «Ел авыр килде, шулай да ниятләгән эшләрне башкарырга иде. Быелгы сезон аграрийлар өчен дә җиңелләрдән түгел. Мондый шартларда терлек санын саклап калу да мөһим», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Әлки. Район башлыгы Александр Никишин хәбәр иткәнчә, хәзерге көндә 6,5 мең гектар уңыш суктырылган (гектардан 30 центнер). Райондагы крестьян-фермер хуҗалыкларында терлекләрнең баш саны аз гына кимүне дә телгә алдылар. Әмма, тулаем алганда, күрсәткечләрне уңай дип билгеләделәр.

Рөстәм Миңнеханов белдергәнчә, авырлыкларга карамастан, республикадагы барлык программалар да үз көчендә кала. «Хезмәтегез өчен рәхмәт сезгә. Ил сезгә – авыл хезмәтчәннәренә таяна», – диде ул.

Моннан тыш Рәис куертылган сөт җитештерү цехында булды. Ул бу елның апрелендә ачылган. Өч ай эчендә 123 тонна куертылган сөт җитештерергә өлгергәннәр.

Нурлат. Нурлат районына эш сәфәре кысасында Рәис кырларны гына карап калмыйча, райондагы кайбер объектлар белән дә танышты.

Кырлар димәктән. Нурлат районы башлыгы Дамир Ишкинеев әйтүенчә, хәзерге вакытта бер гектардан 36 центнер уңыш белән 3 мең гектар җирдә иген суктырылган. Фураж әзерләү эше бара. Районда терлекчелек юнәлешендә эшне көчәйтү кирәк. Моңа җитәкчелек тә аерым басым ясады.

Рөстәм Миңнеханов Нурлатта товар җитештерүчеләрнең продукция күргәзмәсен карады, игенчеләр һәм авыл җирлекләре башлыклары белән дә очрашты. Аграрийлар белән аралашканда, Рәис аларның хезмәт шартлары турында сорашты.

– Киеренке чор. Елы да авыр быел. Уңыш җыю да, азык әзерләү эше дә бик мөһим. Сезгә уңышлар телим! – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис Нурлаттагы су станциясе төзелешен дә карады. Әлеге корылма Татарстанның Экология министрлыгы программасы ярдәмендә төзелә. Программа кысасында 28,4 км суүткәргеч челтәре сузылган, 77 кое булдырылган, 3 яңа скважина ясаганнар.

Бер елдан соң

БОЛГАРДА ЯНӘ «КАРА ПУЛАТ» ОПЕРАСЫ КҮРСӘТЕЛДЕ

Рухи яңарыш чоры. Инде язганыбызча, 15–23 июльдә Болгарда «Яңарыш: дастанның заманча укылышы» фестивале узды. Чараның соңгы көнендә тарихи урында «Кара пулат» операсы күрсәтелде. Аны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә тамаша кылды.

Опера башланганчы «Тормыш рәвеше – мәдәни код» этно-fashion фестивалендә катнашучы дизайнерларның эшләнмәләрен күрсәттеләр, Татарстанның чигелгән картасын тәкъдим иттеләр.

Татарстан Рәисе билгеләп үткәнчә, милли мәдәниятькә ихтыяҗ елдан-ел арта.

– Безнең өчен бу – изге җир. Әлеге фестивальне оештыручылар зур хезмәт башкарган. Әмма иң зур рәхмәтне бүген безнең белән булган һәркемгә җиткерәсем килә, – диде ул, килгән кунакларга мөрәҗәгать итеп.

Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев искәртүенчә, «Кара пулат» операсы фестивальнең мәгънәсен бик төгәл чагылдыра.

– Әлеге фестивальне оештыру идеясе нәкъ бер ел элек, нәкъ шушы урында, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис либреттосына яшь татар композиторы Эльмир Низамов язган «Кара пулат» операсын тыңлаганда барлыкка килде. Әлеге әсәр безнең фестивальнең мәгънәсен төгәл чагылдыра, чөнки аның нигезен халкыбызның Болгар чоры тарихына караган риваятьләре, хикәятләренең заманча укылышы тәшкил итә, – диде ул. – Дастаннарда, риваятьләрдә, легендаларда халыкның күп гасырлык зирәклеге саклана. Сүз үткәнебез турында, бу очракта борынгы бабаларыбыз һәм бу җирнең үткәне турында бара. Без хәзер инде матди мирасыбызны саклаудан рухи яңарыш этабына күчәбез. Һәм моның белән эзлекле рәвештә шөгыльләнәчәкбез.

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе сүзләренчә, зирәклек ул асылташка тиң: беркайчан да картаймый, актуальлеген югалтмый.

– Кешеләр, халыклар һәм дәүләтләр хакына бу зирәклектән файдалана белергә генә кирәк. «Яңарыш: дастанның заманча укылышы» фестиваленең мәгънәсе дә нәкъ менә шуннан гыйбарәт. Безнең чор – төрле халыклар, милләтләр һәм мәдәниятләрнең бердәмләшеп, тарихи тәҗрибә алмашу вакыты. Бу бигрәк тә төрле милләт һәм дин вәкилләре яшәүче Россиядә һәм, гомумән, Җир йөзендә тынычлыкны саклау өчен бик мөһим, – диде Минтимер Шәймиев.

ҖИҢЕЛ БУЛМАЯЧАК

Салым җыю буенча эшне көчәйтергә, «соры» хезмәт базарында тәртип урнаштырырга һәм нефть тармагы оешмалары белән «юл картасы» төзергә. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында ике киңәшмә үткәрде. Аларда керемнәрне арттыру турында сөйләштеләр. Район башлыкларына «өй эше» дә бирделәр.

Бу елның беренче яртысында Татарстанның туплланма бюджетына 252 миллиард сум акча кергән. Шул исәптән үз керемнәр 210 миллиард сум тәшкил иткән. Бу хакта республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының беренче яртыеллыкта бюджет үтәлешенә бәйле уртак киңәшмәсендә әйттеләр.

– Елның икенче яртысында авыррак булачак. Бюджет үтәлешен тәэмин итү елдан-ел катлаулана, – диде Рәис. – Моңа федераль кануннарга бәйле үзгәрешләр дә тәэсир итә. Файдалы казылмалар чыгаруга салым буенча ташламаларны бетерү, кире кайтарылучы акцизны яңача исәпләү бюджет керемнәренә тискәре йогынты ясый. Чыгымнар хезмәт өчен түләүнең минималь күләме үсү хисабына да арта. Без әлеге факторларның барысын бергә 30 миллиард сумга бәялибез.

Киңәшмәдә билгеләп үтелгәнчә, Татарстанда икътисадка бәйле үзгәрешләр дәвам итә. Товар җитештерүчеләр әзер продукцияне озатуның яңа юлларын эзли, импортны алмаштыруга йөз тота. Өстәвенә валюта базарында да тотрыклылык юк. Мондый шартларда кыенлыклар кичерүче предприятиеләр белән эшне тагын да көчәйтергә кирәк, дигән фикер белдерде Рәис. Төп максат да билгеле: бюджетка керемнәрне киметмәс өчен, хәлдән килгән кадәр ярдәм итәргә тырышырга туры киләчәк. «Бу – уртак бурыч һәм без бердәм булып эшләргә тиеш», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Илкүләм проектларны тормышка ашыру да шактый чыгымнар таләп итә.

– Быел әлеге максатларда 44 миллиард сум акча тотылачак, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Шуның 15,1 миллиард сумы – республика акчасы. Федераль үзәк белән төзелгән килешүләрдәге күрсәткечләрнең барысы да үтәлергә тиеш. Барлык авырлыкларга да карамастан, халыкның тормыш шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән республика программалары да дәвам итәчәк. Быел 54,3 миллиард сумлык 44 программа гамәлдә. Шунысын да искәртеп узасым килә: муниципаль берәмлекләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән мондый программалар булмаган төбәкләр дә шактый. Шуңа күрә һәр объектны төзеп бетерергә кирәк. Моның өчен район башлыклары шәхсән җаваплы.

Рөстәм Миңнеханов бурычлар турында да искә төшерде. 1 июльгә алынган мәгълүматларга караганда, салымны үз вакытында түләмәүчеләрнең 13,8 миллиард сум әҗәте җыелган. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бурыч капчыгы 3 миллиард сумга, ягъни утыз процентка диярлек зурайган. Аерым алганда, керемгә салым һәм физик затларның керменә салым буенча әҗәт күләме якынча 50 процентка арткан. Ел башыннан бирле республикадагы 40лап зур предприятие бюджетка түләүләрне киметкән. «Предприятиеләрнең һәр дүртенчесе диярлек зыянга эшли», – диде Рөстәм Миңнеханов. Ул бурычлылар белән эшне көчәйтергә кушты.

Апас, Чирмешән, Яңа Чишмә, Мамадыш, Аксубай, Чүпрәле, Кама Тамагы, Әтнә һәм Тәтеш районнары башлыкларына да эш артачак. Республиканың әлеге районнарында физик затларның керемнәренә салымнан кергән акчаның күләме кимегән. Рөстәм Миңнеханов моның сәбәпләрен ачыкларга кушты.

Утырышта «соры» хезмәт хакы алып эшләүчеләр турында да искә төшерделәр.

– Район башлыкларына рәсми булмаган хезмәт базарын киметүгә бәйле эшне көчәйтергә киңәш итәм. Кемнең ничек эшләгәне күренеп тора бит, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис әйтүенчә, Татарстанда халыкка минималь хезмәт хакыннан да азрак акча түләүче оешмалар саны да кискен арткан. Бу җәһәттән, «кара исемлек»кә кергән Теләче, Мамадыш һәм Кукмара районнары эләкте. Аларга җиңне тагын да ныграк сызганырга туры киләчәк.

Кәефне күтәрә торган яңалык та бар. Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин сүзләренә караганда, республика – салымга керем күрсәткече буенча Идел буе федераль округында алдынгы урында. Бездә эш тә, аш та бар, димәк.

Рөстәм Миңнеханов Татарстан Хөкүмәт йортында «Татнефтехиминвест-холдинг»ның директорлар советы утырышы да уздырды. Агымдагы елның беренче яртысындагы эшчәнлегенә оешманың генераль директоры Рафинат Яруллин йомгак ясады. Рөстәм Миңнехановка яңа проектлар да тәкъдим иттеләр. Мәсәлән, «СИБУР» ҖЧҖ идарәсе әгъзасы Дарья Борисова төзелеш, медицина, транспорт, авыл хуҗалыгы кебек тармаклар өчен полимерлар һәм каучукны яңадан эшкәртеп, чимал алу мөмкинлеге турында сөйләде. «СИБУР» – Татарстанның стратегик хезмәттәше, дип билгеләп үтте Рәис. Эшне тизләтү өчен, «юл картасы» булдырырга да киңәш итте ул.

РӘИСТӘН КИҢӘШ

«Татарстан сезне һәрвакыт көтә». Президент академиясенең XI Җәйге кампусы форумында катнашучыларга Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шулай диде. Иннополис шәһәрендә узган пленар дискуссиядә Рөстәм Миңнеханов катнашучылар белән аралашты һәм яшьләрнең сорауларына җавап бирде.

Җәйге кампус ул – халыкара белем бирү проекты. Форум Россия һәм чит илләрнең иң яхшы студентларын берләштерә. Кампуста быел 200дән артык студент катнашкан, шуларның 40ы – Кыргызстан, Беларусь, Таҗикстан, Казахстан, Кытай, Үзбәкстан, Нигерия һәм башка илләрдән. Шулай ук Президент академиясенең 80 студенты, Татарстаннан 80 һәм Россиянең яңа төбәкләреннән 20 укучы килгән.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, бүген иң мөһиме – үсешкә, яңа бурычларны хәл итәргә, яңа максатларга ирешергә сәләтле кешеләр булу.

– Без бер-беребездән өйрәнәбез. Монда барысы да актив, алдынгы. Бирегә килүегез файдалы булгандыр дип ышанам. Татарстан һәрвакыт сезне көтә, – дип мөрәҗәгать итте ул кампуста катнашучыларга. – Ирешкәннәрдән генә канәгать калырга ярамый, һәрвакыт яңа үрләр яуларга тырышырга кирәк. Тырыш һәм хезмәт сөючән булыгыз! Тәҗрибә мәсьәләсе – иң мөһиме түгел. Әгәр кеше нәрсәнедер үзләштерергә тели икән, бер-ике елдан ул тәҗрибәле белгечтән дә югарырак булачак. Яшь түгел, ә теләк мөһим.

Татарстан Рәисе фикеренчә, яшьләр республикага килергә омтылсын өчен, аларга уңайлы яшәү шартлары булдырырга кирәк.

– Яшьләр бездән китмәсен өчен генә түгел, аларны монда җәлеп итү өчен, заманча шартлар тудыру мөһим. Яхшы эш һәм карьера баскычы буенча үсү мөмкинлеге бирергә кирәк. Бүген үз алдыбызга шундый бурычлар куябыз, – диде ул.

tatarstan.ru

Катнашучыларны Россия Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе ректоры, «Россия – мөмкинлекләр иле» АНО генераль директоры Алексей Комиссаров та сәламләде.

– Президент академиясенең җәйге кампусы быел узмаска да мөмкин иде. Оештыруда төрле катлаулылыклар, үзгәрешләр булды. Ярдәм сорап, Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать иттек, ул бу үтенечкә җавап бирде. Рөстәм Нургалиевич илебездә гамәлгә ашырылган иң яхшы проектларга ярдәм итә, – диде ул.

– Форумда катнашырга теләүчеләр саны елдан-ел арта. Башка илләрдән килүчеләр дә күп. Татарстанга беренче тапкыр килүчеләр бу төбәккә гашыйк булды. Иң мөһиме – яшьләргә кызыклы бурычлар бирү һәм аларның үти алмауларыннан курыкмау. Әгәр мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеге бар икән, ул чакта эшләү дә кызык. Хыялланыгыз һәм аларны тормышка ашырыгыз.

Ләйсән САФИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2014, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 7 статьяның 3 өлешендә «яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү» сүзләрен «, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү яисә муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьяның 2^1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2^1. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү нигезендә төзү, эксплуатацияләү һәм яңарту түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып башкарыла:

1) әлеге мәгълүмат системасы операторы функцияләре тиешле килешүдә каралган чикләрдә, күләмнәрдә һәм срокларда концессионер яисә хосусый партнер тарафыннан башкарыла;

2) концессия килешүе яисә дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү гамәлдә булган чорда концедент яисә хосусый партнер концессионерның яисә хосусый партнерның мондый мәгълүмат системасындагы һәм тиешле килешүләр буенча үз йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 58-ТРЗ

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» 2021 елның 5 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 пунктына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 36 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4) органик продукция җитештерүчеләр – органик продукция җитештерүне, саклауны, маркировкалауны, транспортировкалауны һәм реализацияләүне гамәлгә ашыра торган һәм органик продукция җитештерүчеләрнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән юридик һәм физик затлар, чит ил юридик затлары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар.».

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 59-ТРЗ

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 60-ТРЗ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 9 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 61-ТРЗ

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 44^6 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне бүлү әлеге Кодексның 9^3 нче кушымтасында китерелгән методика буенча башкарыла.»;

2) 9^3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Бюджет кодексына
9^3 нче кушымта

«Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне бүлү методикасы

1. Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне (алга таба – субвенцияләр) бүлү «Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчылары турында» 2004 елның 20 августындагы 113-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы нигезендә Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма-боеру органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) финанс белән тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

2. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме (C_{svod}) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{svod} = \sum_{i=1}^{n} C_{i\ \text{присяжн.}},$$

монда:

$C_{i\ \text{присяжн.}}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тиешле муниципаль район, шәһәр округы (алга таба – i-муниципаль берәмлеге) бюджетына бирелә торган субвенция күләме;

n – дәүләт вәкаләтләре бирелгән муниципаль берәмлекләр саны.

3. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме ($C_{i\text{присяжн.}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{i\text{присяжн.}} = C_{i\text{расч.}} + C_{i\text{резерв}} - C_{i\text{ост.}},$$

монда:

$C_{i\text{расч.}}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенция буенча i-муниципаль берәмлегенең исәпләнгән ихтыяҗы;

$C_{i\text{резерв}}$ – чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бүленмәгән резервтан Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче тарафыннан i-муниципаль берәмлеге бюджетына әлеге Методика нигезендә бүлеп бирелә торган акчалар;

$C_{i\text{ост.}}$ – i-муниципаль берәмлеге бюджетында узган ел ахырына файдаланылмый калган акчалар.

4. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенция буенча i-муниципаль берәмлегенең исәпләнгән ихтыяҗы ($C_{i\text{расч.}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{i\text{расч.}} = P_{i\text{канц.}} + P_{i\text{почт.}} + P_{i\text{сми}},$$

монда:

$P_{i\text{канц.}}$ – i-муниципаль берәмлегенең канцелярия чыгымнары күләме;

$P_{i\text{почт.}}$ – i-муниципаль берәмлегенең почта чыгымнары күләме;

$P_{i\text{сми}}$ – i-муниципаль берәмлегенең Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен (алга таба – кандидатлар исемлекләре) массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруга бәйле чыгымнары күләме.

5. I-муниципаль берәмлегенең канцелярия чыгымнары күләме ($P_{i\text{канц.}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{i\text{канц.}} = H_{\text{канц.}} \times Ч_i \times И_{\text{пц}},$$

монда:

$H_{\text{канц.}}$ – бер кандидатка 10 сумнан артыграк булмаган күләмдә билгеләнгән канцелярия чыгымнары өчен финанс чыгымнары нормативы;

$Ч_i$ – i-муниципаль берәмлегендә суд рәисләре заявкалары буенча кандидатлар исемлекләренә кертелергә тиешле йә i-муниципаль берәмлегендә присяжный утырышчылар булу хокукын югалткан (исемлекләрне үзгәрткән очракта) гражданнарның исәпләнгән саны;

$И_{\text{пц}}$ – чираттагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турындагы федераль закон нигезендә инфляция дәрәҗәсе исәпкә алынган куллану бәяләре арту индексы.

6. I-муниципаль берәмлегенең почта чыгымнары күләме ($P_{i\text{почт.}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{i\text{почт.}} = H_{\text{почт.}} \times Ч_i \times И_{\text{пц}},$$

монда:

$H_{\text{почт.}}$ – бер кандидатка 50 сумнан артыграк булмаган күләмдә билгеләнгән почта чыгымнары өчен финанс чыгымнары нормативы.

7. I-муниципаль берәмлегенең кандидатлар исемлекләрен массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруга бәйле чыгымнары күләме ($P_{i\text{сми}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{i\text{сми}} = H_{i\text{сми}} \times K_{i\text{сми}},$$

монда:

$H_{i\text{сми}}$ – массакүләм мәгълүмат чараларында кандидатлар исемлекләрен бастыру өчен бер басма табак бәясенең Татарстан Республикасында кабул ителгән уртача дәрәҗәсе;

$K_{i\text{сми}}$ – i-муниципаль берәмлегендә кандидатлар исемлекләренең басма табаклары саны.

8. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрне беренче тапкыр бүлгәндәге расланган дәрәҗәдән тыш субвенцияләргә өстәмә ихтыяҗ барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче тарафыннан бүленмәгән резервтан акчалар бүлеп бирелә.

Резервны бүлү ($C_{i\text{резерв}}$) түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$C_{i\text{резерв}} = C_{i\text{уточн.}} - C_{i\text{расч.}},$$

монда:

$C_{i\text{уточн.}}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенциягә i-муниципаль берәмлеге заявкасы буенча төгәлләштерелгән (Россия Федерациясе Югары Суды каршындагы Суд департаменты эшләгән тәртип нигезендә) ихтыяҗ.

Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенция, әгәр $C_{i\text{уточн.}}$ $C_{i\text{расч.}}$ дән кимрәк булса, i-муниципаль берәмлеге бюджетына заявка нигезендә күчерелә, ә Татарстан Республикасы бюджетында тотылмый калган акчалар суммасы муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетлары арасында алга таба яңадан бүлү өчен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бүленмәгән резервны арттыруга җибәрелә.

9. Заявкалар саны чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган субвенцияләр суммасыннан артык булган очракта, ассигнованиеләрне бүлү ($C_{i\text{присяжн.уточн.}}$) түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$C_{i\text{присяжн.уточн.}} = C_{svod} / C_{svod\ \text{уточн.}} \times C_{i\text{уточн.}},$$

монда:

$C_{svod\ \text{уточн.}}$ – барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округлары буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләргә төгәлләштерелгән ихтыяҗ.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 62-ТРЗ

Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

Үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4);

2) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» 1996 елның 28 мартындагы 483 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 4);

3) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 елның 24 июнендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 6);

4) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 16 декабрендәге 128-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш);

5) «Икътисадый үсеш өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 27 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 4);

6) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2009 елның 9 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1);

7) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 2011 елның 30 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш);

8) «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 20 июлендәге 61-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);

9) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш).

2 статья

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 63-ТРЗ

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 14 һәм 15 пунктлар өстәргә:

«14) Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән очракларда терлекләрне исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

15) физик һәм юридик затлар җир кишәрлекләреннән, биналардан, урыннардан, төзелмәләрдән, корылмалардан файдаланып терлекләр үстерү, асрау һәм чалу, ветеринария контроле (күзәтчелеге) үткәрелергә тиешле товарлар җитештерү, эшкәртү һәм саклау эшчәнлеген гамәлгә ашырганда файдаланыла торган объектларның – җир кишәрлекләренең, биналарның, урыннарның, төзелмәләрнең, корылмаларның зоосанитария статусын билгеләү – объектларны сакланылмаган объектларга яисә зоосанитария яклавы түбән дәрәҗәдә булган объектларга керткәндә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 19^2 статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасында (алга таба – «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законы) күрсәтелгән очраклардан тыш.»;

2) 16 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. **Терлек продукциясен җитештерү, эшкәртү, күчерү, саклау һәм сату»;**

б) 2 өлештә «әзерләү, эшкәртү, саклау, ташу» сүзләрен «җитештерү, эшкәртү, ташу, саклау» сүзләренә алмаштырырга;

3) 18 статьяның 1 өлешендә:

а) өченче абзацта «хайваннарны тикшерү өчен китерергә» сүзләрен «тикшерү һәм исәпкә алу өчен хайваннар янына керә алу мөмкинлеген (йорт яны җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан торак урыннарга керә алу мөмкинлегеннән тыш) бирергә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«– «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 19^1 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, терлекләрне маркировкалауны тәэмин итәргә;

– «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 19^1 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, терлекләрне исәпкә алуны гамәлгә ашыручы затларга терлекләрне маркировкалауның һәм исәпкә алуның ветеринария кагыйдәләрендә билгеләнгән исемлек буенча һәм срокларда терлекләрне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләр тапшырырга.»;

4) 19 статьяда:

а) 1 өлештә «1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга.

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 64-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтаның 2 пунктына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) индустриаль (сәнәгать) парк булдыру, һәм (яисә) аны үстерү, һәм (яисә) аны модернизацияләү, һәм (яисә) аны реконструкцияләү буенча инвестиция проекты Татарстан Республикасы шәһәр округы территориясендә гомуми күләме кимендә 350 миллион сум булган инвестицияләрне, Татарстан Республикасы муниципаль районы территориясендә кимендә 15 миллион сум булган инвестицияләрне күздә тота. Шул ук вакытта инвестицияләрнең гомуми күләме индустриаль (сәнәгать) паркның потенциаль резидентлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инвестицияләрне исәпкә алып билгеләнә;»;

2) 3 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 65-ТРЗ

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 2 пунктта «җирлекнең яисә шәһәр округының җирле әһәмияттәге объектларын» сүзләрен «җирле әһәмияттәге объектларны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «җирлек яисә шәһәр округы составына керә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 пунктта «җирлекнең яисә шәһәр округының функциональ зоналары» сүзләрен «функциональ зоналар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 өлешнең 1 пунктында «җирлекнең, шәһәр округының урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларының» сүзләрен «урнаштыру өчен планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектларның» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 өлештә:

а) 1 пунктның беренче абзацында «җирлекнең, шәһәр округының» сүзләрен төшереп калдырырга, «планлаштырылучы җирле әһәмияттәге объектлары» сүзләрен «планлаштырыла торган җирле әһәмияттәге объектлар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «җирлек яисә шәһәр округы составына керә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 4^1 өлештә «җирлек яисә шәһәр округы составына керүче» сүзләрен төшереп калдырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 66-ТРЗ

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.21 статья өстәргә:

«2.21 статья. **Режим (төп әзерлек дәрәҗәсе) кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыруны күздә тотучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү**

1. Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән режим (төп әзерлек дәрәҗәсе) кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыруны күздә тотучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәгән өчен, әгәр дә бу хокук бозуларда җинаять җаваплылыгы гамәлләре булмаса яисә алар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә административ җаваплылыкка китермәсә, –

кисәтү ясала яисә гражданнарга – бер меңнән алып дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып кырык мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.

2. Шул ук гамәлләрне (гамәл кылмауларны) кабат кылган өчен –

гражданнарга – биш мең сум күләмендә; вазыйфаи затларга – кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга өч йөз меңнән алып биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.20» саннарын «2.11 – 2.21» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяда:

а) 4 өлештә «Кодексның» сүзеннән соң «2.21,» саннарын өстәргә;

б) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әлеге Кодексның 2.21, 3.6 (Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда) статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының вазыйфаи затлары төзи.»;

в) 10 өлештә «3.10 статьясында» сүзләрен «2.21, 3.10 статьяларында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 14 статьяда «2.19, 2.20» саннарын «2.19 – 2.21» саннарына алмаштырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар ту-

Ахыры 4 нче биттә >

Ахыры. Башы 3 нче биттә >

рында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш), «2.19, 2.20» саннарын «2.19 – 2.21» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 67-ТРЗ

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) түбәндәге эчтәлекле 3^1 – 3^3 пунктлар өстәргә:

«3^1) Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче (үткән) гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәттә (хезмәттә) булучы (булган) гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәве шарты белән, күрсәтелгән территорияләрдә булучы (булган) Россия Федерациясе хокук саклау органнары хезмәткәрләре (эшләүчеләре), күрсәтелгән территорияләрдә хезмәт функцияләре һәм башка шундый ук функцияләр башкаручы (башкарган) гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары;

3^2) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән гражданнар, аларның Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашуы һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәве шарты белән, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм күрсәтүче оешма белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган) гражданнар, аларның күрсәтелгән территорияләрдә махсус хәрби операциядә катнашуы шарты белән, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары;

3^3) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә 2014 елның 11 маеннан башлап Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы Халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында хәрби гамәлләрдә катнашкан затлар, шулай ук әлеге затларның гаилә әгъзалары;»;

б) 8^3 – 8^5 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 өлештә:

а) 10^2 пунктта «ятим балаларның» сүзләрен «инвалид балаларның, ятим балаларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 17 – 21 пунктлар өстәргә:

«17) хәрби хезмәткәрләрне акчалата тәэмин итү һәм «Хәрби хезмәткәрләрнең акчалата тәэминаты һәм аларга аерым түләүләр бирү турында» 2011 елның 7 ноябрендәге 306-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларга аерым түләүләр бирүне тәэмин итү;

18) әлеге статьяның 1 өлешендәге 3^1 һәм 3^2 пунктларында күрсәтелгән затларга ташламалар, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр бирү;

19) әлеге статьяның 1 өлешендәге 3^3 пунктында күрсәтелгән затларга ташламалар, социаль гарантияләр һәм компенсацияләр бирү;

20) әлеге статьяның 1 өлешендәге 3^1 һәм 3^2 пунктларында күрсәтелгән затлар (аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) арасыннан булган гражданны хәбәрсез югалган дип тану;

21) әлеге статьяның 1 өлешендәге 3^1 һәм 3^2 пунктларында күрсәтелгән затлар (аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) арасыннан булган гражданны үлгән дип игълан итү.».

2 статья

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең 3^1 һәм 3^2 пунктлары, 2 өлешенең 17, 18, 20 һәм 21 пунктлары нигезләмәләренең гамәли көче 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 68-ТРЗ

Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) егерменче абзацта «кеше сәламәтлегенә» сүзләреннән соң «зарарлы йогынты» сүзләрен өстәргә;

б) егерме алтынчы абзацта «атмосфера һавасы сыйфатының экологик нормативларына» сүзләрен «атмосфера һавасы өчен әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты нормативларына» сүзләренә алмаштырырга;

в) кырык бишенче абзацта «кеше сәламәтлегенә» сүзләреннән соң «аның зарарлы йогынтысын» сүзләрен өстәргә;

г) кырык җиденче абзацта «табигать комплекслары һәм объектлары урнашкан» сүзләрен «табигать комплекслары һәм объектлары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектлары, табигый экологик системалар урнаша торган» сүзләренә алмаштырырга;

2) 83 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«83 статья. **Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда атмосфера һавасын саклау таләпләре**

1. Капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлаганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда, эксплуатацияләгәндә, сүткәндә атмосфера һавасы сыйфатының гигиена нормативларын һәм атмосфера һавасы өчен әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты нормативларын үтәү тәэмин ителергә тиеш.

2. Капиталь төзелеш объектларын җирлекләр, шәһәр округлары чикләрендә проектлаганда, төзегәндә атмосфера һавасын пычратуның фон дәрәҗәсе, шул исәптән атмосфера һавасы пычрануны җыелма исәпләү нәтиҗәләре буенча алынганы, һәм шушы эшчәнлекне башкарганда аның сыйфаты үзгәрешен фаразлау исәпкә алынырга тиеш.

3. Атмосфера һавасы сыйфатына тискәре йогынты ясый ала торган капиталь төзелеш объектларының проектлау документациясендә атмосфера һавасына пычраткыч матдәләрне чыгаруларны киметү һәм аларны зарарсызландыру чаралары каралырга тиеш.

4. Атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарыла торган капиталь төзелешнең яңа һәм (яисә) реконструкцияләнгән объектларын эксплуатациягә тапшырганда атмосфера һавасына чыгарып ташлауларның, иң чик мөмкин булган чыгарып ташлауларның технологик нормативларын, физик йогынтыларның иң чик мөмкин булган нормативларын арттыру рөхсәт ителми.

5. Атмосфера һавасын саклау кагыйдәләрендә каралган газлар чистарту җайланмалары һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны тикшереп тору чаралары булмаган капиталь төзелеш объектларын төзү, эксплуатацияләү тыела.

6. Эшләүләре климатның һәм атмосфераның озон катламының уңайсыз үзгәрешләренә китерергә, кешеләрнең сәламәтлеге начараюга, үсемлекләрнең генетик фондын һәм хайваннарның генетик фондын юкка чыгаруга китерергә, әйләнә-тирә мохит өчен кире кайтарылмаслык нәтиҗәләр китереп чыгарырга мөмкин булган капиталь төзелеш объектларын проектлау, төзү тыела.»;

3) 85 статьяда:

а) исемендә татарча текст үзгәрешсез кала;

б) 3 өлештә татарча текст үзгәрешсез кала;

4) 87 статьяда:

а) исемендә «зарарлы» сүзен төшереп калдырырга;

б) «зарарлы» сүзен төшереп калдырырга;

5) 90 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«90 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш иткәндә пычраткыч матдәләрне чыгарып ташлауларны җайга салу**

Эшчәнлекләре нәтиҗәсендә атмосфера һавасы сыйфатына тискәре йогынты ясый торган җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килә торган юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар, куллану процессында атмосфера һавасы сыйфатына тискәре йогынты ясый торган калдыклар барлыкка килә торган физик затлар мондый калдыклар белән «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эш итәргә тиеш.»;

6) 94 статьяның 3 өлешендә «җирләрне сугару һәм ашлау» сүзләрен «сугару һәм башка мелиоратив чараларны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга, «санитар законнар» сүзләрен «санитария-эпидемиология таләпләре» сүзләренә алмаштырырга;

7) 95 статьяның 3 өлешендә «Җирләрне агып төшүче сулар белән сугару һәм ашлау» сүзләрен «Сугару һәм башка мелиоратив чараларны гамәлгә ашыру өчен агып төшүче сулардан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

8) 96 статьяның 3 өлешендә «мелиоратив эшләр әйләнә-тирә мохитне саклау, су объектларын һәм аларның су җыю мәйданнарын яклау» сүзләрен «мелиоратив чаралар әйләнә-тирә мохитне, су объектларын һәм аларның су җыю мәйданнарын саклау» сүзләренә алмаштырырга;

9) 105 статьяның 4 өлешендә «(зарарлы)» сүзен төшереп калдырырга;

10) 132 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

1. Әлеге Закон, үз көченә керүнең әлеге статьяда башка срогы билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «г» пунктчасы, 6 – 8 һәм 10 пунктлары 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 69-ТРЗ

Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 пунктчасында «республика максатчан программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 статьяның 3 пунктында «мелиоратив ышыклагыч урман утыртмалары» сүзләрен «агроурманмелиоратив утыртмалар, агрофитомелиоратив утыртмалар» сүзләренә алмаштырырга;

3) 12 статьяның 6 пунктында «табигый комплексларына» сүзләрен «табигый экологик системаларына, табигать комплексларына һәм үсемлекләр, хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге булган объектларына» сүзләренә алмаштырырга;

4) 25 статьяда:

а) 1 пунктта «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту» сүзләрен «җирләрнең үзенчәлекләрен яхшырту, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктның 3 пунктчасында «мелиоратив ышыклагыч урман утыртмаларын» сүзләрен «агроурманмелиоратив утыртмаларны» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 70-ТРЗ

Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә һәм әлеге өлкәдә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруда аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) җиңел такси – гавами фрахтлау шартнамәсе нигезендә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган җиңел автомобиль;

2) рөхсәт – Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә физик зат тарафыннан җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын бирә торган электрон документ;

3) физик зат – «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы һәм индивидуаль эшкуар булмаган зат;

4) җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы – Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Закон нигезендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә физик зат;

5) җиңел таксига заказ бирү хезмәте – фрахтлаучы һәм фрахтчы тарафыннан алга таба җиңел таксины фрахтлауның гавами шартнамәсен төзү максатларында фрахтлаучы булырга ниятләгән заттан җиңел таксига заказ алу һәм (яисә) фрахтчы булырга ниятләгән затка җиңел таксига заказ тапшыру эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы бирелгән юридик зат яисә индивидуаль эшкуар.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру һәм җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләү;

2) рөхсәт бирү, аның гамәлдә булуын туктатып тору, юкка чыгару һәм торгызу тәртибен билгеләү;

3) вәкаләтле органга Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гаризаны яисә хәбәрнамәне һәм аларга кушып бирелә торган документларны җибәрү тәртибен билгеләү;

4) җиңел такси йөртүчеләр турындагы белешмәләр составын һәм вәкаләтле органга җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы тарафыннан әлеге белешмәләрне җибәрү тәртибен билгеләү;

5) вәкаләтле орган җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар региональ реестрына һәм (яисә) җиңел таксилар региональ реестрына кертkән үзгәрешләр турындагы белешмәләрне алуның техник мөмкинлеге булмау хакындагы хәбәрнамәне вәкаләтле органга җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан җибәрү тәртибен билгеләү;

6) җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләргә һәм багаж ташучыларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр, аларның бәясе һәм алар өчен түләү кагыйдәләре турындагы белешмәләрне үз эшчәнлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланмыйча гамәлгә ашыручы җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан урнаштыру тәртибен билгеләү;

7) җиңел таксига заказ бирү хезмәте үз эшчәнлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланмыйча гамәлгә ашыруны күздә тоткан очракта, Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан урнаштыру тәртибен һәм чыганакларын билгеләү;

8) физик зат булган җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы (рөхсәт алу турында гариза бирергә ниятләгән зат) (алга таба – заказчы) тарафыннан вәкаләтле органга, заказчы җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлаганчы, заказчыга җиңел такси турындагы белешмәләр җиңел таксилар региональ реестрына кертелгән җиңел таксины файдалануга бирү, аны бирү срогы турында хәбәрнамә тапшыру, шулай ук аны исәпкә алу тәртибен билгеләү;

9) җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы тарафыннан җиңел таксига заказ бирү хезмәтенә җиңел такси йөртүченең Федераль законның 19 статьясындагы 3 өлешенең 8 пунктында каралган таләпләрне бозуы турында белешмәләр тапшыру тәртибен билгеләү;

10) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау;

11) Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

12) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләре**

Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) рөхсәт бирү, аның гамәлдә булуын туктатып тору, юкка чыгару һәм торгызу;

2) җиңел таксига заказ бирү хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын бирү, җиңел таксига заказ бирү хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукының гамәлдә булуын туктатып тору, бетерү һәм торгызу;

3) җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар региональ реестрын, җиңел таксилар региональ реестрын һәм җиңел таксига заказ бирү хезмәтләре региональ реестрын (алга таба – региональ реестрлар) алып бару;

4) җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифлары турындагы белешмәләрне урнаштыру өчен Федераль законның 24 статьясындагы 2 өлешендә каралган сайтны билгеләү;

5) Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә каралган гаризалар һәм хәбәрнамәләр, әлеге гаризаларга карата карарлар кабул итү турындагы хәбәрнамәләр һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар региональ реестрыннан, җиңел таксига заказ бирү хезмәтләре региональ реестрыннан өземтәләр рәвешләрен раслау;

6) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;

7) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру**

1. Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

2. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеге, җиңел таксилар региональ реестрына алар турында белешмәләр кертелгән транспорт чараларыннан файдаланып, юридик затка, индивидуаль эшкуарга яисә физик затка бирелә торган һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар региональ реестрындагы язма белән расланган рөхсәт нигезендә, рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тормау яисә юкка чыгармау шарты белән, гамәлгә ашырыла.

3. Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга рөхсәт биш елга, физик затларга рөхсәт биш елга йә, физик зат рөхсәт алу турындагы гаризада азрак срокны күрсәткән очракта, шул срокка бирелә.

4. Җиңел таксига заказ бирү хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы бирелә торган срок биш ел тәшкил итә.

6 статья. **Җиңел таксига карата куела торган таләпләр**

1. Җиңел такси Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш. Җиңел такси кузовының төсләр гаммасы ак яисә сары төсләр гаммасына туры килергә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлешендә каралган мәгълүматны ике үлчәмле штрихлы код (QR-код) рәвешендә яисә җиңел такси салонында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге мәгълүмат урнаштырылган сайтның адресы турындагы белешмәләрне урнаштыру аша бирү мөмкинлеге билгеләнергә мөмкин.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән җиңел такси буларак файдаланыла торган транспорт чарасының экологик классына карата өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.

7 статья. **Региональ реестрлар**

1. Региональ реестрларны алып бару, җиңел таксилар федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

2. Җиңел таксилар федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган белешмәләр составы, вәкаләтле орган тарафыннан белешмәләрне мондый мәгълүмат системасына тапшыру тәртибе, сроклары, ысуллары Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган җиңел таксилар федераль дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

8 статья. **Аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар территорияләрендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру үзенчәлекләре**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән, аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар территорияләрендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрне тәкъдим итү һәм (яисә) рәсмиләштерү өчен җиһазландырылган урыннардан тыш, мондый хезмәт күрсәтүне тәкъдим итүне тыю, аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар территорияләрендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру үзенчәлекләре билгеләнергә мөмкин.

9 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

1. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәгә таянып башкарыла.

2. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып Федераль законның 30 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү тора.

3. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

4. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә таянып даими рейд үткәрелә. Даими рейдны үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нигезләмә белән билгеләнә.

10 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 20 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 4 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 77 (I өлеш).

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

2. Вәкаләтле орган тарафыннан 2023 елның 1 сентябренә кадәр бирелгән җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәтләр аларның гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы, әмма күрсәтелгән датадан биш елдан күбрәк түгел, гамәлдә булалар.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 71-ТРЗ

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 2^2 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«2^2. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның торак урыннары белән тәэмин ителү хокукы әлеге Законның 2 статьясы нигезендә исемлеккә кертелгән башка затларныкыннан өстен була.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 72-ТРЗ

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясындагы 8 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), «дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган юридик зат» сүзләрен «торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында күрсәтелгән затлар» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 73-ТРЗ

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 3 өлешендә «гомумтаралган файдалы казылмалардан» сүзләреннән соң «һәм минераль эчәргә яраклы сулардан» сүзләрен өстәргә;

2) 14 статьяның 2 өлешендә «илкүләм гарантия системасында» сүзләрен «кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итүнең илкүләм гарантия системасында» сүзләренә алмаштырырга, «поручительлек фондлары)» сүзләреннән соң «һәм дәүләт (муниципаль) микрофинанс оешмалары» сүзләрен өстәргә.

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2023 елның 28 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 74-ТРЗ

ӨЛЕШЕҢӘ ТИСЕН КӨМЕШЕҢ

Мәгариф

Яңа уку елыннан башлап мәктәпләрдә көмеш медальләрне кире кайтарырга җыеналар. Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов фикеренчә, әлеге яңалык укучыларны да, әти-әниләрне дә сөендерәчәк. Медаль горурлык билгесе генә түгел, укырга кергәндә өстенлеге дә бар.

Хәзерге вакытта медаль дигәнең бары «5ле»гә укучыларга гына бирелә. Рәсми исеме «Укудагы уңышлары өчен» дип атала. Аны алу өчен мәктәптә отличник булу гына җитми. Рус теле һәм математикадан БДИны ким дигәндә 70 баллга тапшырырга кирәк. Югыйсә алтын медальдән колак кагачаксың. Ә көмешен бирү 2014 елда бетерелде. Анысы аттестатта нибары ике «4ле»се булганнарга бирелә иде. Дәүләт Думасының Мәгариф комитеты рәисе урынбасары Яна Лантратова фикеренчә, кызыктырсаң, балалар яхшырак укыячак.

tatarstan.ru

Алтын медаль алучыларга өстәмә балларны һәр вуз үзе билгели. Әйтик, Мәскәү дәүләт университетында 6 балл каралган. Көмеш медаль өчен исә 2–3 балл бирмәкчеләр.

– Алтын янында көмеше дә булырга тиеш. Спортта беренче урынга – алтын, икенче урынга көмеш медаль бирәләр бит. Нишләп әле мәгарифтә дә бирмәскә? Көмеш янына бронзасы да кирәк, – ди Балтач районындагы Салавыч лицееның биология укытучысы Резеда Бадгиева.

Буа районының Кайбыч мәктәбе рус теле һәм әдәбияты укытучысы Нурлисә Хәсәнова да, кирәк, ди. Моны ул әти-әниләр фикереннән чыгып әйтә.

– Мин инде мәктәптә 35 елдан артык эшлим. Көмеш медальләр бетерелгәч, әти-әниләр арасында: «Их, баламның бер генә «4ле»се чыкты, ник көмешне бетерделәр икән», – дип үкенүчеләр дә булды. Кире кайтарулары бик әйбәт. Бер-ике «дүртле»се чыкканнар да нәүмиз булып калмаячак. Көмеш медаль алу да – горурлык бит, – ди Нурлисә Хәсәнова.

Шул ук вакытта укытучыларның, көмеш медальнең мәгънәсен күрмим, БДИ булганда, аның кирәге юк, дигәннәре дә бар. Янәсе, тырышып укыган бала гел «5ле»гә укый ала. Бер-ике «4ле» белән калмаячак.

Айнур Ибәтуллин быел Балтач районының Арбаш мәктәбен тәмамлаган. Ул башта мәктәп эскәмиясеннән үк армиягә китәргә җыенган иде, хәзер укуын алга таба дәвам иттермәкче. Аның фикеренчә, медальләрнең берсе дә кирәкми.

– Медальгә бетермәдем, әмма белемем медальлеләрнекеннән бер дә ким түгел, – ди Айнур. – Алтынның да мәгънәсе калмады дип уйлыйм. Ул бары үзең өчен генә кирәк. Синдә бармы ул, юкмы – калганнарның исе дә китми моңа. Мәктәптә кемдер яхшы укый, кемдер уртача, шул ук вакытта кемгәдер белем бөтенләй кирәкми. «3–4ле»гә укучылар киресенчә, тормышка яраклырак, минемчә. Ни өчен шулай соң? Җавабы бик гади. «5ле»гә укучы, контроль эш буласын белсә, бер атна алдан әзерләнә башлый. Өйрәнә, укый, ятлый. Үз тормышына вакыты калмый аның. Ә «3ле»гә укучы нишли? Мәктәптән кайткач, ял итә, туп тибә. Контроль эш җиткәч, ничек эшләп чыгарга икән, дип баш вата башлый. Андыйлар проблеманы бик тиз хәл итү ягын таба. Медальдә түгел хикмәт.

Икътисадчы булып эшләүче Гөлүзә Рәхимованың заманасында ике фәннән генә «4ле»се чыккан. Ул мәктәпне көмеш медальгә тәмамлаган. «Татар теле, физкультура укытучыларның миңа карата карашы да икенчерәк иде. «Сөйкемле сөяк» булу да кирәк шул. Шулай итеп, алтын медаль миңа тәтемәде. Башта моны бик авыр кичердем. Аның каравы көмеш медаль алдым. Тимер кисәге генә түгел бу! Тырышып укыгач, медале дә булырга тиеш. Һәр хезмәт бәяләнергә тиеш», – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Әнис ГАЛИМҖАНОВ, КФУ доценты, физика-математика фәннәре кандидаты:

– Көмеш медальләрне кире кайтарырга кирәк. Беренчедән, югары уку йортларына укырга кергәндә, өстәмә баллар биреләчәк. Икенчедән, рухи ягы да бар. Соңгы елларда символларга карата хөрмәтебез бик нык кимегән иде. Хәзер бөтен нәрсә акчага корылган. Алтын-көмеш медальләр, грамоталар урынына акча гына бирсеннәр, диләр. Бар нәрсәне дә акчага алыштыруның бик начар икәнлеген җәмгыять әкренләп аңлый башлады. Акчага эквивалент булмаган әйберләрне дә кайтарырга кирәк. Медальләрне кире кайтару – шуның бер мисалы гына. Авылда балалар Сабан туе уздырдык. Анда сабыйлар рәхәтләнеп уеннарда катнашты. Сабыйларда шатлана белү дигән нәрсә бар әле. Ә олыгая барган саен, шушы халәтне җәмгыять үзе бетерә. Моны кабат терелтеп булырмы? Вакыт кирәк.

Спорт

rubin-kazan.ru

Буш кайтмадылар

1 очко белән башладылар. Бер еллык тәнәфестән соң премьер-лигага әйләнеп кайткан «Рубин» беренче очрашуын Мәскәүдә уздырды һәм «Локомотив» белән ничьяга уйнады. Яңа килгән футболчылар сөендерде, аның каравы Рәшит Рәхимов уенчылары җиңүне кулдан ычкындырды.

Тарихка күз салсак, моннан 20 ел элек – 2003 елның 16 мартында «Рубин»ның премьер-лигада тәүге очрашуын уздырганы искә төшә. Мәскәүдә ЦСКАга каршы узган уенда Корбан Бәрдыев командасы 0:4 исәбе белән оттырды. ЦСКАның ике тубын – хәзер «Оренбург»ның баш тренеры булып эшләүче Иржи Ярошик, тагын берсен – «Зенит»ның остазы Сергей Семак, дүртенчесен соңгы елларда Корбан Бәрдыевның ярдәмчесе вазыйфасын башкарган Дмитрий Кириченко кертте.

Инде үзебезнең көннәргә әйләнеп кайтсак, шимбә көнне Мәскәүдә «Локомотив»ка каршы узган очрашуда «Рубин» 3 нче минутта ук исәпне ачты. Төп командада тәүге уенына чыккан Яшел Үзән егете Илья Рожков пас бирде, ә командага әле генә килеп кушылган албан уенчысы Мирлан Даку беренче тубын кертте. Сүз уңаеннан, 18 яшьлек Рожков «Рубин»ның премьер-лигада нәтиҗәле пас биргән иң яшь уенчысы булып танылды. Моңа кадәр иң яше булып быел Италия чемпионатын откан һәм Европадагы иң талантлы уенчылар исемлегенә кергән Хвича Кварацхелия санала иде. Мирланд Даку керткән туп исә «Рубин»ның ил чемпионатларындагы 2800 нче голы булып тарихка кереп калды. Беренчесен 1958 елның 20 апрелендә Херсонның «Спартак» капкасына Игорь Игнатов керткән булган.

Даку гол белән генә тукталып калмады, Джоэль Фамейе туп керткәндә, аңа пас та бирде һәм очрашуның иң яхшы уенчысы исеменә лаек булды. Гомумән алганда, команданың яңа футболчылары яхшы уен күрсәтә алды. Угочукву Иву көндәшләргә һөҗүм оештырырга комачау итсә, Игор Вуячич Артем Дзюбага туп кертергә ирек бирмәде. Әмма «Локомотив»ның оста уенчылары Дзюбадан башка да җитәрлек. Әнә шулар исәпне ике мәртәбә тигезләп, «Рубин»ны 3 түгел, ә 1 очко белән кайтарып җибәрделәр. Араларында узган ел Казанда уйнап, быел Мәскәүгә күчкән Илья Самошников та бар.

Аңлашыла инде, беренче уеннан соң ук Рәшит Рәхимов командасының нәрсәгә сәләтле булганын чамалавы кыенрак. Әмма «Рубин» премьер-лига гына түгел, Россия Кубогында да чыгыш ясый. Беренче һәм премьер-лига арасындагы аерманы 3–4 уенчы белән генә каплап булмый. Димәк, яңа футболчылар комачау итмәячәк. Инде янә тарихка күз салсак, 2003 елгы сезонның соңгы очрашуында «Рубин»ның янә ЦСКАга каршы уйнаганы искә төшә. 1 ноябрьдә Татарстан башкаласында узган ул матчта җиңү яулап, Казан командасы чемпионатта өченче урынны алган иде.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

БАЛЛЫ БАЛАГА – АКЧА

АКЫЛЛЫ БАШЛАРНЫ ТУГАН ЯКЛАРЫНДА КАЛДЫРЫП БУЛЫРМЫ?

Бер фәннән 100 баллга – 100 мең, ике фәннән 200 баллга – 200 мең, өч фәннән 300 баллга – 300 мең сум. КФУ имтиханнарда яхшы нәтиҗәләргә ирешкән абитуриентларны әнә шундый акчалата премия һәм «Универсиада авылы»нда яшәү урыны белән җәлеп итеп, Татарстанда калдырмакчы була. Бу ни дәрәҗәдә нәтиҗәле алым булыр? Без шул хакта сораштык.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Алинә ГАЙНЕТДИНОВА, БДИда химиядән 100 балл җыйган абитуриент:
– Мин моны бик яхшы кызыксындыру чарасы дип уйлыйм. Яшьләргә үз илендә, туган ягында калырга, монда кирәкле белгеч булырга бик әйбәт стимул. Шәхсән үзем дә укуымны КФУның химия факультетында дәвам иттерергә ниятлим. Һәм, билгеле, мин дә бу премиягә өметләнәм.

Альберт ШАКИРОВ, журналист, блогер:
– Мондый премияне уңай нәтиҗәләргә китерә торган алым дип саныйм. Шуны онытмаска кирәк: сүз кечкенә мәктәп балалары – 17–18 яшьлек егет-кызлар турында бара. Нәрсә генә дисәк тә, 100 мең – күп акча. Әле бит бу – ким дигәндә. Аңа бер дигән ноутбук та алып була, теләсәң, стажировкага китәсең. Кыскасы, кайсы яктан карасаң да, файдасы бар. Мотивация ягыннан карыйбыз икән, бөтен нәрсәне белеп туган хәзерге заман яшьләренең акылында ул бик төгәл сигнал булып кабул ителәчәк. Тәк, укырга керүгә, 100 мең сум премия бирделәр, димәк, безнең илдә, безнең мәгариф системасында белемле, тырышкан кешенең кадере бар, дәрәҗәсе югары, дигәнрәк уйлар киләчәк башына. Зур тормышның нәкъ шундый уңай хисләрдән башланып китүе бигрәк тә кадерле. Ул бит инде тәүге хезмәт хакың кебек. Андый премияләрне заманында минем дә алган булды. Матур истәлек булгач, нәрсәгә тотканыма кадәр хәтердә.

Ринат ХӘЙРУЛЛИН, укытучы:
– 100 меңнең генә файдасы булмас, дип уйлыйм. Миңа калса, әллә ни зур сумма түгел ул. Бала, шуңа алданып, Санкт-Петербург, Мәскәү вузларының дипломын югалта бит. Ярар, 100 меңен алыр да укып чыгар ул. Ләкин монда аңа мөнәсәбәт нинди булыр соң? Гомумән, безнең системага белгечләр кирәкме ул? Иң элек, укып, белем алып чыккан кешегә мөнәсәбәтне үзгәртергә кирәк. Мисаллар күз алдында бит: чит илләргә күпме кеше китте һәм китә. Ә безгә укыган кеше кирәк түгел кебек. Шул ук мәгариф системасын алсаң да, укытучыга хөрмәт юк дәрәҗәсендә. Шундый мөнәсәбәтне күргән баланың монда каласы килерме? Шикләнәм.

Диана ГЫЙЛЬФАНОВА, Мәскәү дәүләт педагогика университетын тәмамлаган Казан кызы:
– Миңа калса, бюджет урыннарының санын арттыру күпкә яхшырак булыр иде. Күп кенә абитуриентлар Казан һәм Мәскәүдәге уку йортларын чагыштыра да икенчеләренә укырга керергә җиңелрәк булуын аңлый. Казанда бюджет урыннары коточкыч аз, ә кайбер җирдә бөтенләй юк бит. Аннан, мондый премия – бик яхшы идея. Әмма бу премияне алган студентлар беренче семестрдан ук укуын ташламас дип кем әйтә? Моннан тыш, КФУдагы түләүле бүлекләрдә уку елына уртача 150 мең сум тирәсе дип беләм. Теге премия бер ел өчен түләргә дә җитми бит…

Раил ШӘМСЕТДИНОВ, Казан энергетика көллиятенең информатика укытучысы:
– Абитуриентларны җәлеп итү өчен яхшы алым дип саныйм. Ләкин бер нәрсә бар: мондый тәҗрибәне башка уку йортлары да файдалана бит. Шул ук Мәскәү вузларында да бар ул. Бу очракта КФУның дәрәҗәсе беренче урындадыр дип уйлыйм мин. Акча өчен түгел, КФУда белем алу өчен керәләр анда. Шулай булуына карамастан, кайбер абитуриентларны Татарстанда калдырырга ярдәм итәр ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сан

Быел Татарстанда **8** кеше БДИның ике фәненнән 100әр балл җыя алган. Бер фәннән йөз балл туплаучыларның саны – **180**. 19 июльгә КФУга документлар тапшыручылар арасында БДИда бер фәннән йөз балл туплаучыларның саны – **323**, ике фәннән йөзәр балл туплаучыларныкы – **18**, өч фәннән йөзәр балл туплаучы – **1**.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Август-Лениногорск» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты **Сәлахов** Алмаз Минсәгыйть улы, «Государев Амбар» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сәлахов** Вәсил Вазых улы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Хәбетдинов** Рәшит Вәсил улы, «Таллы-Бүләк» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы механизаторы **Хәсәншин** Илһам Сәлахетдин улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Рубин» футбол клубы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең спорт базасы азык-төлек блогы калькуляторы **Камалиева** Энҗе Искәндәр кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Рубин» футбол клубы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төп командасы администрациясенең склад мөдире – администраторы **Рябцев** Николай Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ИЯЛӘНГӘН ЭШ

Менә шундый кеше

«Мин дә аптырыйм. Миңа да аптырыйлар», – ди 42 елдан артык чылбырлы тракторда эшләүче Тәлгать Һадиев. Татарстанның атказанган механизаторы, Балтач районының мактаулы гражданины, Шеңшеңәр авылы егетен күп еллар беләм. Яшьтән алдынгы булды, «ДТ» тракторында эшләүчеләр арасында гел макталды.

«Маяк» хуҗалыгының эшчәнлеге турында язганда, исеме һәрчак беренче була иде. Район күләмендә җиңгән еллары да, икенче-өченче урыннарны алганнары да дистәләп булгандыр.

– Хәзер инде алай ук эшләп булмый, куәтле техникалар күп бит, – ди Тәлгать, бу турыда сүз чыккач. – Теге чорда чиратлашып җиңә торган «ДТ» йөртүчеләрнең күбесе пенсиягә чыгып бетте инде. Күп урында бу тракторлар сезонлы гына кулланыла бит. Ә бездә әле барыбер елның 365 көнендә эш табыла, авырмасаң, техникаң төзек булса, тик торган юк. Кыр эшләренә дә чыгам, фермада да эш бетми. Элек «ДТ»лар колхозларның төп эш көче иде шул. Ул елларда ял да, бәйрәм дә күрмәдек. Язгы-көзге кыр эшләре, кышын урманда бер көн – колхозга, бер көн хуҗалыкка агач кисәргә, алып кайтырга барасы, алардан бушаган көннәрдә салам тарттырасы иде. Анысы соңгы елларда гына бетте әле. Хәзер инде ялын да бирәләр, шифаханәгә бушлай юлламасын да… Ел саен диярлек әйтәләр, әмма кайчак үзем баш тартам, ел саен шифаханәгә барырга мин колхоз рәисе түгел бит, дим, алай да 4–5 тапкыр барганмындыр…

– Кырык ике елдан артык нигә һаман «ДТ»да эшләдең, уңайлырак тракторлар бар, аннан соң куәтле техникалар кайтты бит, аларга утырасың килмәдемени? – дип сорыйм Тәлгатьтән.

– Ун ел саен яңа трактор биреп бардылар. Мин башкасын сорамадым, алар тәкъдим итмәде, йөрттем дә йөрттем инде, – ди ул, елмаеп. – Эшкә бит ияләнергә генә кирәк. Аннан соң кыенлыгын сизмисең дә. Кемнәрдер, бу уңайсыз, авыр тракторда ничек эшли икән, дип аптырыйдыр инде. Мин үзем дә кайчакта, кайберәүләрнең хезмәтен күреп, бу эштә ничек эшлиләр икән, дип аптырыйм, нәкъ шуның кебек инде…

Тәлгать – механизаторлар нәселеннән. Әтисе Миңнәхмәт тә егерме елдан артык чылбырлы тракторда эшләгән.

– Беренче елда әти белән кара-каршы бер тракторда чәчү чәчтек әле, – дип искә ала ул. – Миңа тәүлек буе чәчү бер генә ел эләкте. Элек гел шулай эшләгәннәр…

Әниләре Рәүфә фермада терлек караган. Бу тырыш гаиләдә үскән балаларның барысы да авылда калган. Дүрт егет техника иярләсә, кызлары Руфинә башта сыер сауган, бозаулар тудыру бүлегендә эшләгән, хәзер лаеклы ялда. Бөтенесе авылны сайлау өстенә, башка чыккан егетләр барысы да бер урамда, бер тирәдә өйләр салган. Тәлгатьләргә генә колхоз фатиры туры килгән, аны да инде өстәп, зурайтып, үзгәртеп бетергәннәр. Башкаларга бергәләп төзегәннәр. Барысы да бүген күп итеп маллар үстереп, үз көчләре белән көн күрә, үзара ярдәмләшеп, ашы да, эше дә уртак, дип яшиләр. Төп нигезне дә ташламаганнар: бүген анда төпчекләре Илфат гаиләсе белән килгән туганнарга кадер-хөрмәт күрсәтеп яши.

– Безне шушындый туганчылыклы итеп үстергән әти-әнигә бик рәхмәтле без. Шөкер, алар үзләре дә бик матур, тигез гомер итте, без бик бәхетле гаиләдә үстек, яшәдек. Кызганычка, әти-әни ике ел элек бер-бер артлы вафат булдылар, башта ковид әтиебезне алып китте, аннан әнине җирләдек… Әле яшьләре дә әллә ни олы түгел иде, – ди Тәлгать.

Ярый әле балаларының, аларның гаиләләренең мул, матур тормышта яшәүләрен күреп, үзләреннән соң «туганлык» дигән олы мирас калдыруларын, игелекле балалар үстерүләрен аңлап, бәхет төмен татып китә өлкән Һадиевлар. Бөтен балалары алар үрнәгендә яши – бәхет формуласын беләләр…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Автор фотосы

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Сагыну

Мин авылны сагынам. Үз авылымны. Барыбыз да шулайдыр инде ул.

Әллә нинди сәер сагыну бу. Теш сызлавы сыман сагыну. Җанның әллә кайсы бер төпкеленнән сиздермичә генә сыгылып чыга да бар дөньяңны томалый, бөтен булмышыңны биләп ала, һәрбер күзәнәгеңә кереп сулкылдый һәм син үзең дә, тирә-ягыңдагылар да тоташ әрнүдән генә торгандай тоела башлый. Теш сызлавын ничектер басып та була бугай әле, ә җан сулкылдавына дәва юк. Теш сызлавын кешеләргә сөйләп аңлатып та була, аңлыйлар, чөнки һәрберсендә утыз ике теш бар, аларның кайсы да булса кайчан да булса авыртмыйча калмый, үз башына төшкән, үзе кичергән газапны кеше аңлый да, уртаклаша да ала.

Ә җан әрнүен аңлатуы авыр. Чөнки һәркемнең дә җаны берәү генә. Һәм һәркемнең дә җаны әрнү-сызлануларга сәләтле түгел. Сагыну тойгысы да һәркемгә дә бирелмәгән. Бирелсә дә, тигез бирелмәгән. Үзе сагынмаган кеше башкаларның хәлен аңлый алмый. Сагынуын да, сызлануын да, башкасын да. Кешенең хәлен бары тик шул ук халәтне аннан да ныграк кичергән кеше генә аңлый ала. Моң-зарын да, шатлык-куанычын да. Хәтта бәхетен дә. Бәхетленең хәлен аңлау мөмкинлеге бары тик аннан да бәхетлерәк кешеләргә генә бирелгән. Бәхетсезрәкләре аңлый алмый, алар соклана яки көнләшә генә ала. Кайгысын да шулай. Кешенең кайгысын тулысынча аңлый һәм уртаклаша алу өчен үзеңнең кайчан да булса шуннан да авыррак кайгы кичергән булуың кирәк. Юк икән, син кызганырга, юатырга, ярдәм итәргә мөмкинсең, ә аңлый алмыйсың. Аңламагач, хәлен уртаклашып та булмый. Ә чынлабрак уйлап карасаң, без бит гомер буена янәшәбездә яшәгән якыннарыбызны да тулысынча аңлап җитәлмибез. Чынлабрак уйлап карасаң, без кешеләрнең теше сызлавын гына аңларга һәм уртаклашырга сәләтле.

Мин авылны сагынам… Үз авылымны…

Шәһәрдә яшәгәндә, бу тойгы аеруча нык көчле була икән. Кайчагында йөрәк төбендә калган кисәү шикелле әрнетеп йөри. Балачакның иң кадерле мизгелләрен казып чыгара. Син үзең дә вакыт машинасында шул чорга кайтып, шул малайлар арасында йөргән шикелле тоеласың, тик алар белән аралашып кына булмый, кулларыңны сузуга ук юкка чыгалар. Кыен булып кала.

Ә авылда шундый рәхәт иде. Сыерларның тояк тавышына, мөгрәвенә уянып китәсең. Чыбыркы шартлап куя, кемнеңдер һай-һайлап мал куганы ишетелә. Күршеләрнең быдыр-быдыр хәл белешкәне. Ә син җиңелчә генә киерелеп аласың да икенче ягыңа борылып ятасың, йокының ләззәтле куенына кабат чумарга дип талпынасың һәм кинәт сикереп торасың. Сыерлар көтүдән кала лабаса! Ни эләксә, өстеңә шуны элеп чыгып йөгерәсең. Син җитешүгә, инде көтү авыл читенә җиткән була. Көтүне күргәч, сыерлар аерылып калмый, барыбер барып кушылалар, шуңа тыныч күңел белән борылып, кабат йортыңа чабасың – сарыкларны чыгарырга кирәк, аннан бозауларны озатырга…

Көтү куу, көтү каршылауның үз ләззәтләре бар аның. Иртән бөтенесе урамда була, бер-ике сүз белән булса да аралашасың, хәл белешәсең. Ә кичләрен алдарак барып, көтү кайтуын көткән атлы булып ял итәсең, авыл яңалыкларын уртаклашасың, сөйләшәсең…

Көтү генә түгел инде, авылның һәрбер эше үзенә күрә бер Сабан туе шикелле аның. Чәчү булса, басулар шаулап тора. Бөтен халык шунда, кырык эшен кырык якка ташлап киләләр – көннәр әйбәт чакта чәчеп калырга кирәк. Чөгендер белән бәрәңге җирләрендә җәйләрен дә кеше өзелми. Һәркемнең үз кишәрлеге булса да, табыннарны бергә коралар, шулай ямьлерәк тә, тәмлерәк тә була. Кеше пешереп алып килгән ят ризык ул һәрвакыт татлырак булып тоела.

Уңыш җыйганда да басулар гөрли. Хәтта шәһәр җирләреннән ят машиналар кайта, күрше-тирәләрдән әллә нинди комбайннар килә. Ә ашарга җыелган вакытлар олы бер бәйрәмгә әверелә. Монда җыр-моң да ишетелә, уен-көлкегә дә урын табыла, хәтта көрәше дә читтә калмый. Дәртле инде халык безнең якта.

Ә печән вакытлары… Бер карасаң, шундый тыгыз чор бит инде ул, бернәрсәгә дә вакыт табылмаска тиештер сыман – көн әйбәт торганда эләктереп калырга кирәк. Тик авыл халкы шунда да җай таба: чабынлыклары бер тирәдәгеләр аш-суны бергә әзерли, уенын-кызыгын бергә кушып, бәйрәмдәге кебек утыралар. Чапканда да, җыйганда да, ташыганда да бер-берсенә ярдәм итешеп, сый-хөрмәт күрсәтеп эшлиләр.

Бәрәңге алулар да, сугым чоры да… Гомумән, авыл тормышының һәр мизгеле эштән тора, ә һәрбер эш бәйрәм белән үрелеп бара. Хезмәттә дә, табында да чит-ятлар юк монда, барысы да үз кеше, бар да газиз…

Сагынмаслык та түгел шул. Өстән-өстән сөйләгәндә генә дә шулай бит ул, ә үзең шул тормышта яшәгәндә, бөтенләй рәхәт дөнья. Һәр мизгеле яшәү белән тулы, һәр мизгеле якты, мәгънәле…

Сагынам дип елап яту егетләр эше түгел. Сагынасың икән – бар, күр, яшә. Мин авылга кайттым.

Авылның җаны булып яшәгән абзыйларның күбесе юк инде, калганнары картайганнар. Урамнарда киләчәк булып йөгерешеп йөргән малай-кызларның да күбесе читкә киткән. Чәчү-уру-җыю чорлары да ничектер сизелмичә генә үтә. Печән өсте дә юк. Мал тотмагач, печән кирәкмени… Маллар да юк. Җәен-кышын, язын-көзен урамнарда чыр-чу килеп йөргән балалар да юк. Йортлар матур. Коймалар да матур. Авыл шул коймалар артына кереп бикләнгән дә матур йортларда яши. Авылдашлар белән сирәк күрешәбез.

Тагы ни дип әйтим соң… Мин авылда яшим. Үз авылымда…

Мин авылны сагынам. Үз авылымны. Теш сызлаган сыман.

Барыбыз да шулайдыр инде ул.

ӘЛЕ ЯРЫЙ ӨМЕТ БАР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гомәр ХӘЯЛИЕВ
(Яшел Үзән районының Мамадыш-Әкил авылы):
– Безнең авылда фермер бар. Печәнне дә, ашлыкны да аңардан сатып алабыз. Печәнне алып, кышка җитәрлек әзерләп куйдык инде. Уртача зурлыктагы печән рулонын 1300 сумга алдык. Гаиләбездәге барлык кешенең пай җирләре – шушы ук фермерда. Шуның өчен ул безгә ел саен 1,5 тонна ашлык бирә. Быел да шуңа өметләнеп торабыз. Печән начар булды дип әйтеп булмый. Чапкан кешегә әле дә бар, тик чабасы гына килми инде хәзер. Печәнне үзләре чабып әзерләгән кешеләр юк хәзер авылда. Хәер, мал асраучысы да шуның кадәрле генә калып бара. Сөт бәясе төшү дә нык аяк чалды. Авылда малларын киметүчеләр бар, көзгә тагын булыр, дип уйлыйм. Әйтик, без кыш көне өч сыер сава идек. Язын берсен бетерергә мәҗбүр булдык. Инде тагын берсен бетермичә булмас, дибез. Берни дә эшләп булмый, иң мөһиме – саулык булсын.

Әнисә ГАТИЯТОВА
(Саба районының Олы Кибәче авылы):
– Быел печәнне картым белән үзебез әзерләдек. Ирем кул чапкычы белән чапты да, трактор белән түкләттек. Үзебезнең атыбыз бар. Печәнне аның белән дә, трактор белән дә алып кайттык. Менә шулай искечә яшәп ятабыз әле без. Хәзер безнең кебекләр калмады инде. Яше дә, өлкәне дә сатып кына ала. Печән быел күп түгел, ләкин елга буйларында бар. Иренмәгән кешегә чабарга була. Сыерыбыз, атыбыз, ике үгезебез, дүрт бозавыбыз бар. Яшебез дә шактый инде. Үземә – 65 яшь. Икебезнең дә аяклар авырта, таякка таянып йөрибез. «Менә шушы аксак-туксак ике кеше 27 түк печән әзерләде», – дип, үзебезне үзебез шаярып мактап йөрибез инде. Әле ярый булышырга улыбыз да бар. Аллага шөкер, печән җитәрлек әзерләдек. Узган елдан да шактый калган иде, үзебездән артса, балаларга да бирербез, дип тырыштык. Бер кызыбыз биш сыер асрый, икенчесенекенең үгезләре бар. Ашлык сатучыбыз күршедә генә яши. Акчасын арпаның бер килосына 8 сумнан күптән биреп куйган идек инде. Менә әле шушы көннәрдә генә 32 капчык арпа алып чыктык. Ләкин инде хәзер арпа бәясе 12 сумга җиткән. Саламны да шул фермердан алырбыз дип торабыз. Шуңа күрә терлекләрне бетерү турында уйламыйбыз әле. Киресенчә, кызлар, тана бозауларын сата алмагач, безгә төшереп куйдылар. Мал саны артып тора, бик күңелле бездә.

Марсель МОСТАФИН
(Азнакай районының Беренче Май авылы):
– Быел печән бик начар үсте. Эссе көннәрдә кибеп бетә дип чабып аткан идек, түкләткәнче яңгырлар ява башлады. Алып кайта алмый калдык. Күпме чыгасын әлегә әйтеп булмый. Узган елдан калган 60лап рулон бар. Моннан тыш, авылдашлардан узган елгы печәннең бер рулонын 1500 сумнан тагын егермене сатып алдык. Бәлки шушылар барысы да җитәр дә. Арпаны июньдә үк алып куйган идек. 8 сумнан 11 тоннадан артык кайтарттык. Бәясе 93 мең сумга якын булды. Кышка кергәнче тагын алырга кирәк булачак, дип торабыз. Чөнки маллар ишле. Биш сыерыбыз, дүрт үгезебез, биш бозавыбыз, 23 сарыгыбыз бар. Сөтне 13 сумнан сатабыз. Бик арзан инде бу бәя. Тапшырганда күп сөт тапшырабыз кебек, ләкин акча ала башлагач, кәефебез төшә. Чыгымнар күп бит. Безнең якларда 350–370 кг люцерна рулоны 2900 сумнан, 270–300 килолысы 2600 сумнан йөри. 3100 сумга тәкъдим итүчеләр дә бар. Узган елгы печәнне 2200 сумга сатучылар бар. Без печәнне үзебез чабабыз, тик аны рулонга җыяр өчен 350 сум түлибез. Техникасына да ягулыгы, ремонты кирәк. Шуңа күрә безнең кебек яшьләр мал асрамый да инде. Әле бер-ике ел элек кенә көтүгә 60–70ләп мал чыга торган иде. Быел нибары 38 терлек куыла. Авылда терлек саны елдан-ел кими.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шәмсия АЛИМОВА
(Чүпрәле районының Шланга авылы):
– Быел безнең тирәләрдә үлән үскән вакытта яңгырлар булгалады. Шуңа күрә печән дә яхшы үсте. Терлек асраган халык аны җитәрлек әзерләп калырга тырышты. Элеккеге кебек урманнарга чыгып печән чабучы абзыйлар юк инде хәзер, шуңа күрә кемдер сатып ала, кемдер тегеннән-моннан юнәтә. 3 центнерлы печән рулонын – 1000, 5 центнерлысын 1500 сумга саттылар. Узган елгы арпа һәм бодайның килосын халык 8 сумнан ала. 21 июльдән сөт тапшыру бәясе 16 сумга менгән, дигән хәбәр килде әле. Аңа кадәр 14 сумнан тапшырган идек. Бездә терлек күпләп асрыйлар, тик ел башыннан аларның саны шактый азайды. Мәсәлән, безнең авылда 46 сыерга кимеде. Сәбәпләре төрле инде аның. Беренчедән, сөт бәяләре түбән, чыгым күп. Икенчедән, бишсигез ел элек мини-ферма төзер өчен, күп кеше грант алган иде. Менә хәзер аларның дәүләт алдындагы бурычы бетте һәм сыерларының берничәсен киметтеләр. Күпчелеге шул хисапка азайды. Өченчедән, авыл картая. Өлкәнәеп, малларын бетерүчеләр арта. Без үзебез дә ике сыердан берне генә калдырдык. Бер сыерыбыз авыргач, бетерергә туры килде дә яңаны алып тормадык.

Фәнис ӘХМӘТХАНОВ
(Арча районының Корайван авылы):
– Безнең якларда печән уңышы уртача булды, дип әйтсәк, дөресрәк булыр. Аз да түгел, күп тә түгел. Мин үзем 170 баш терлеккә җитәрлек печән әзерли алдым. Ләкин башка еллардагы шикелле халыкка сатарлык юк. Моннан тыш, күбрәк күләмдә сенаж салынды. Шуңа күрә печән җитәр, дип уйлыйм. Бәлки икенче катыннан яхшы уңыш алып булыр. Бу көннәрдә яуган яңгырлар бик кирәк иде. Без өметләнәбез инде, әле ярый авыл халкын өмет яшәтә. Халыкның күпчелеге печәнне сатып ала. Арча районында 3 центнерлы печән рулоны 1500 сум тора, 5 центнерлысы 2000 сум тирәсе йөри. Люцерна кыйммәтрәк. Фермерларга терлеген бетерү җиңел түгел. Аларның барысы да диярлек кредитка, бурычка чумган. Терлеген дә бетерсә, аны ничек түләсен ул? Ә менә халык бетерү яки киметү турында күп сөйли. Болай да мал тотучылар аз инде. Хәзерге вакытта халыктан сөтне 18–19 сумнан алалар. Без сөт заводларына 21–22 сумга тапшырабыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Авыл уңганнары

ИШЕГАЛДЫ – ГӨЛЛӘР ИЛЕ

Балтач

Кили авылында яшәүче Гариповлар тирә-ягын чәчәкләргә күмгән. Чүлмәкләрен санап бетерерлек түгел. Хәзер гаилә башлыгы Җәмил дә хатынына: «Моның кадәр чәчәкне кая куясың? Тозлыйсыңмы, кайнатма ясыйсыңмы?» – дип шаяртмый инде. Матурлыкны бергәләп тудыралар.

Гариповларның ишегалдындагы гүзәллекне, үткән-сүткәндә, капкадан башын тыгып караучылар да аз түгел. Авылга кайткан саен, төшеп кенә кара инде шулкадәр тамашаны, дип, мине дә түбән очка чакыргалады авылдашларым. Чүлмәкләр ишәйгән саен, Резедага соклану арта гына бара. Аның әйбәт килен икәнлеген дә беләбез. Инсульт кичергән 86 яшьлек каенанасын, церебраль параличлы 58 яшьлек каенапасы Асияне тәрбияли ул. Дини кануннар буенча яшәгәч, башкача мөмкин дә түгелдер. Күрше Кариле авылыннан килен булып килүенә 24 ел икән инде. Җәмиле белән өч бала үстерәләр. Төпчекләре Сәмиргә – 6 яшь. Шамилләре быел армиядән кайткан. Кызлары Камилә Казанда эшли.

– Каенанам белән килешеп торабыз. Тормыш булгач, төрлесе була анысы, әмма ямьсезләнешкәнебез юк. Җәмилем бик әйбәт. Ул хатынны – хатын, әнине әни итеп күрә белә. Хатын-кызның бәхете ирдән тора. Әйдә, бакчаны болайрак бизибез, дип, идеяләр дә биргәли. Балчыкны ул алып кайта. Ул да гүзәллек ярата, – ди Резеда.

Чәчәкләрен карау өчен элегрәк иртәнге сәгать 4тә торырга туры килгән аңа. Районагы сөт-май заводына эшкә киткәнче, бакчага чыгып, чүбен утаган, суын сипкән. Өйдәгесен дә тәртиплисе бар дип, быел 18 ел хезмәт куйган эшеннән киткән икән. «Арып китсәң, чәчәкләр янында ярты сәгать кайнашу барысын да оныттыра», – ди.

– Чәчәк яратмаган хатын-кыз бармы икән ул? Аны һәрберебез ярата бит. Элек бакчада гына үстерә идем. Петунияләр күрдем дә чүлмәкләргә утырта башладым. Ишегалдын матурайтасым килде. Аннан калибрахоа, эустома, бальзамин, гортензия һәм башкаларны сатып алдым. Башка елларны чәчәкләрем шаулап үсә иде. Быел әллә эссе булгангамы, бик күпереп утырмыйлар. Махсус урында яшь үсентеләр тотам. Картаеп китсәләр, ямьсезләнә башласалар, искеләрен яңага алыштырам. Шулай итеп төрләндереп торам, – дип елмая ул.

Резеданың чәчәкләргә булган мәхәббәте әнисе Һидаядан күчкән. Ул да гөлләр белән мәш килә. Һәр почмагы, өе – гөлчәчәк. Кайда яңа төр орлык күрсә, утыртып карый икән. Үсентеләрен Резедага да бирә. «Зинһар, акча түгеп алма», – ди икән. Резеда үсентеләрне баштарак Марий Эл Республикасына барып алып кайткан. Хәзер инде районда да чәчәк үстереп сатучылар бар. Шуңа күрә еракка эзлисе юк. «Кайда чәчәк сатсалар, шунда – Резеда», – диләр аның турында. Үзе исә чәчәк үстереп сату белән шөгыльләнергә җыенмый. Моның өчен вакыт һәм акча кирәк. Дөрес, чыгымнар болай да күп, әмма матурлык хакына акча җәл түгел.

Ә менә утырткан чәчәкләренең берсенең дә үсмичә калганы юк икән. Чәчәкләрен ашлап тора. Югыйсә чәчәк атмаячаклар. Арада эустома кебек көйсезләре дә бар бит. Чәчәкләр дә авырый. Үзен бакчачы дип санамаса да, интернетта тиешле дәвасын таба.

– Кырау төшә, дисәләр, моның кадәр чүлмәкне нишләтәсең? – дип сорадым аннан.

– Баштарак беседка, теплицага куеп тордык. Соңгы кырауда барысын да ишегалдында калдырган идек. Кайберәүләрнең бәрәңге, кыярларын кырау сукты, ә безнекенә тимәгән. Чүлмәкләрне каядыр урнаштырып бетереп тә булмый, – ди ул.

Автор фотосы

Сәрия МИФТАХОВА

Киңәш-табыш

Гортензияне ашлау ысулы

Әлеге чәчәкләр әчкелтем туфрак ярата. Шуңа күрә төпләренә ылыс сипсәң була. Ашлау өчен Резеда түбәндәге ысулны куллана:

Ун литр суга 1 литр кефир кушып сибәргә. Шул ук күләмдәге суга ярты пачка лимон кислотасы салырга да мөмкин.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 305

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+